Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

3 октябрь 2019 ел № 30

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча 2019 елның 24 сентбрярендәге 7468и номерлы комиссия бәяләмәсенә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалану -- «гомуми мәйданы 600 кв.метрдан артмаган амбулатор-сырхауханә учреждениеләренә», җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт төрләре классификаторы буенча коды № 3.4 - «сәламәтлек саклау», Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Фрунзе ур., з/у 5А адресы буенча урнашкан 244 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча халык тыңлаулы билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 18 октябре 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә бер айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 18 октябренә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.М. Токарев